**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Күзкәй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**08.12.2016 ел** **Күзкәй авылы** **№ 14/6**

***Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү турында***

«Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчү) чикләү турында» 22 ноябрь, 1995 ел, № 71-ФЗ Федераль закон, «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнарның массакүләм җыелу урыннарын һәм югары куркыныч чыганакларының урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кузкәй авыл җирлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалардан һәм объектлардан янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр араның минималь күләменен билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән һәр оешма һәм (яисә) объект өчен якындагы территорияләрнең чикләре схемасын расларга.

3. Якын-тирәдәге территорияләр чикләренә кадәр араны исәпләү ысулын билгеләргә.

4. Әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән оешмалардан һәм (яисә) объектлардан янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр керү (чыгу) алдыннан 10 метр ераклыктагы минималь араны билгеләргә, әгәр объектның койма белән әйләндереп алынган территориясе булса, аңа керү юлыннан.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Күзкәй

авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү турында»2013 ел, 31 май, 1/5 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның күчермәсен этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, аның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенә кабул ителгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча җибәрергә.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Советы рәисе Э.Р. Гәрәев